**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2021 елның 9 декабреннән № 16-120

Яңа Чишмә муниципаль районының 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Исхакова Л. К. «Яңа Чишмә муниципаль районының 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Яңа Чишмә муниципаль районының 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.К. Исхакова мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Яңа Чишмә муниципаль районының 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразын хупларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елда районның инвестицион җәлеп итүчәнлеге буенча эшне көчәйтергә;

- бизнес алып бару һәм үстерү, шулай ук район территориясендә бизнес өчен конкурентлы мохитне стимуллаштыру өчен уңайлы шартлар тудырырга;

- авыл җирлекләренең тотрыклы үсешенә, Яңа Чишмә муниципаль районы халкының мәшгульлеген һәм тормыш дәрәҗәсен арттыруга ярдәм итәргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, барлык төр милек формасындагы предприятие һәм оешма җитәкчеләренә 2022 елга һәм 2023-2024 елларга план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән кирәкле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы В. М. Козлов